# ДЕМОНСТРАЦИОННЫЕ ЗАДАНИЯ ЗАКЛЮЧИТЕЛЬНОГО ЭТАПА
## Северо-Восточной олимпиады школьников по родным языкам
## (профиль – «Родной (татарский) язык и литература»)

**10-11 КЛАССЫ**

**1 нче бирем. Ике мәкаль языгыз, аларның транскрипциясен ясагыз. Иң югары балл – 4.** // Задание 1. Подберите на родном языке две пословицы и дайте их звуковую транскрипцию. Максимальный балл – 4.

**Г. Зәйнәшеваның «Бәхет юллары» шигырен укыгыз. 2-4 нче биремнәрне үтәгез.**

**Бәхет юллары**
**Г. Зәйнәшева**

Юлда йөрсәм, никтер күңелем
Яктыра матур уйлардан.
Нинди серләр бардыр офыкта?
Чакыра әллә кайларга.

Илем иркен, юллар киң, озын,
Иге-чиге юк юлларның.
Тели күңелем һәр кешенең
Җирдә бәхетле булганын.

Юлга чыксам, җырлап барам,
Моң уяна йөрәкләрдә.
Әллә сөйгән ярым көтәме икән?
Көтә бәхет дигән төбәкләрдә.

Юлда йөрсәм, никтер күңелем
Очар коштай канатлана.
Әйтерсең лә балачагым
Һәм яшьлегем кабатлана!

**2 нче бирем. Шигырьдә бирелгән *юлда, җырлап, яшьлегем* сүзләрен 1) төзелешләре ягыннан тикшерегез. Сүз тамыры, ясагыч һәм мөнәсәбәт белдерә торган кушымчаларын, сүз нигезен тиешле тамгалар белән билгеләгез; 2) аларны үзләре бәйләнгән сүзләр белән күчереп языгыз; 3) җөмләдәге синтаксик вазифаларын күрсәтегез. Иң югары балл – 6.** // Задание 2. Разберите по составу следующие слова из приведенного выше стихотворения: ***юлда, җырлап, яшьлегем,*** обозначьте морфемы соответствующими знаками. Определите, какую синтаксическую функцию они выполняют и с какими словами связаны. Максимальный балл – 6.

**3 нче бирем. Шигырьнең икенче строфасындагы *иркен, киң, озын, юк, һәр* сүзләренең синоним һәм (яки) антонимнарын языгыз. Иң югары балл – 5.** // Задание 3. Подберите синонимы и (или) антонимы к словам *иркен, киң, озын, юк, һәр* из второй строфы стихотворения. Максимальный балл – 5.

**4 нче бирем. Шигырьдә бирелгән *уйлардан, иге-чиге, бәхетле, коштай, канатлана, балачагым* сүзләрен 1) төзелешләре ягыннан тикшерегез. Сүз тамыры,**

**ясагыч һәм мөнәсәбәт белдерә торган кушымчаларын, сүз нигезен тиешле тамгалар белән билгеләгез; 2) ясалыш ысуллары ягыннан (тамыр, ясалма, кушма, парлы) төркемләгез. Иң югары балл – 5**. // Задание 4. Определите морфемный состав следующих слов из стихотворения: ***уйлардан, иге-чиге, бәхетле, коштай, канатлана, балачагым.*** Обозначьте морфемы соответствующими знаками. Сгруппируйте слова в зависимости от способа их образования. Максимальный балл – 5.

**Рафис Гыйззәтуллинның «Көтелмәгән сорау» дип аталган әсәрен укыгыз һәм 5-7 нче биремнәрне үтәгез.**

Рәсим күтәрелеп караган иде, алгы партада утыручы Илһамның ручкасына күзе төште. Гади генә дә түгел, бизәкләп, сырлап ясалган иде ул. Тәрәзәдән сузылган кояш нурларында алтындай елык-елык килә. Уйнаклаган нурлар Рәсимне: «Синең андый ручкаң юк», – дип үчеклиләр сыман иде.

Тора-бара әлеге ручка малайның тәмам тынычлыгын алды, аңа карап утыра торгач, кыңгырау шалтыраганны да ишетмәде, малайлар ишектән йөгереп чыга башлагач кына, кайда утыруын абайлап алды.

Әнә Илһам да, ручкасын кесәсенә салып, ишеккә юнәлде. Рәсим аның артыннан көнләшеп карап калды. Шул минутта күңелендә бер уй кузгалды. Әлеге ручканы үзенеке итү теләге иде ул.

Тәнәфес вакытында да, кыңгырау шалтырап, икенче дәрескә кереп утыргач та, малай гел шул хакта баш ватты. Дәрес буена күзе алдагы партада – Илһам кулына сыенган ручкада булды. Аңа караган саен, теге кара теләк арта гына барды.

Дәресләр тәмамлануын белдереп, янә кыңгырау тавышы бирелүгә, Рәсим ашыкмый-кабаланмый урыныннан торды. Сумкаларына дәфтәр, китапларын тутыру белән мәшгуль булган Илһам ручкасының юкка чыкканын сизми дә калды. Рәт арасыннан узганда, Рәсим үзенең тынычлыгын алган ручканы эләктергән иде инде. Ничек шулай оста, тиз эләктергәндер, соңыннан үзе дә гаҗәпләнде ул моңа. Аны-моны уйламаган Илһам, сумкасын күтәреп, класстан чыгып китте.

Рәсимнән дә бәхетле малай юк иде бу минутларда. Бизәкле ручка аның кесәсенә кереп кунаклаган иде.

Өйләренә дә кош тоткандай очынып кайтып керде. Кесәсеннән алып, ручканы әйләндереп-тулгандырып карарга кереште. Бигрәкләр дә матур, язарга да ипле икән. Шушы ручканы үзенеке итүенә гел сөенеп, шатланып йөрер кебек иде малай. Тик куанычы озакка бармады.

Барысына да сеңелесе Илгизә сәбәпче булды. Абыйсының кулындагы ручканы кай арада күреп алган диген. Янәшәсенә килеп басты да шәрран ярып сорап та куйды:

– Ай, нинди матур ручка. Кайдан алдың аны, абый?

Бу көтелмәгән сорауга ни-нәрсә дип тә җавап бирә алмады Рәсим. Алгы бүлмәдән әнисе килеп чыкты. Ул да, улы кулындагы ручканы күреп, шул ук сорауны кабатлады. Рәсим тәмам коелып төште. Әле бая гына ручканы үзенеке итүенә сөенеп туя алмаган иде. Хәзер җавап бирә алмый, башын аска иеп тик басып тора. Йөзе комач кебек кызыл.

– И-и-и, улым, күреп торам, кеше әйберенә тигәнсең. Кара аны, иясенә илтеп бир, – диде әнисе һәм, кисәк кенә борылып, бүлмәдән чыгып та китте.

Рәсим янә учына күз салды. Ручка элеккечә балкып күренми иде инде.

Икенче көнне Рәсим класска иң беренче булып килеп керде. Керүгә кулындагы ручканы Илһамның партасына куйды.

Озакламый бер-бер артлы сыйныфташлары да килә башлады. Ниһаять, ишектә Илһам да күренде. Ул ручкасын күргәч, балкып, елмаеп җибәрде.

– Онытып калдырганмын икән ич. Югалттым дип торам, – дип сөйләнде үзе. – Абыем бүләге...

Тик аның сүзләренә игътибар итүче генә булмады. Рәсим генә, хуҗасы кулына күчкәннән соң, янә элеккечә балкып, нурланып торган ручкага карап, җиңел сулап куйды.

**5 нче бирем. Тексттан түбәндәге мәгънәләргә ия фразеологизмнарны язып алыгыз:** ***1) борчуга салу; 2) нәрсә эшләргә белми аптырау; 3) бик шатланып; 4) иркенләп, тынычлап калу.*** **Иң югары балл – 4. // Задание 5.** Выпишите из представленного выше отрывка текста фразеологизмы со значениями: *1) борчуга салу; 2) нәрсә эшләргә белми аптырау; 3) бик шатланып; 4) иркенләп, тынычлап калу.* Максимальный балл – 4.

**6 нчы бирем. Түбәндәге җөмләнең 1) төрен; 2) хәбәрлекләр санын; 3) бәйләүче чараларын языгыз. Иң югары балл – 5. //** Задание 6. Укажите вид сложного предложения, определите, из скольких частей оно состоит, назовите способы и средства связи между ними. Максимальный балл – 5.

*Тора-бара әлеге ручка малайның тәмам тынычлыгын алды, аңа карап утыра торгач, кыңгырау шалтыраганны да ишетмәде, малайлар ишектән йөгереп чыга башлагач кына, кайда утыруын абайлап алды.*

**7 нче бирем. Рафис Гыйззәтуллинның «Көтелмәгән сорау» дип аталган текстына таянып, «Ни өчен кеше әйберенә тияргә ярамый?» дигән темага 10-15 җөмләдән торган эссе языгыз. 1) Проблеманы формалаштырыгыз һәм үз фикерегезне билгеләгез; 2) автор позициясен күрсәтегез; 3) тексттан фикерләрегезне раслый торган 2 дәлил китерегез. Иң югары балл – 15 . //** Задание 7. Напишите эссе из 10-15 предложений по произведению Р. Гиззатуллина «Көтелмәгән сорау» на тему «Почему нельзя брать чужие вещи?». В эссе вы должны вначале сформулировать проблему. Опираясь на исходный текст, поясните это, приводя примеры. Выразите свою собственную позицию по указанной проблеме. Работа должна характеризоваться смысловой цельностью, связностью и последовательностью изложения, не содержать ошибок. Максимальный балл – 15.

**8 нче бирем. Текстны татар теленә тәрҗемә итегез. Иң югары балл – 30. //** Задание 8. Переведите текст с русского языка на родной. Обратите особое внимание на адекватность передачи содержания текста оригинала и правильность выбора формы выражения мысли на родном языке в каждом переведенном предложении. Максимальный балл –30.

**ВОЛК**

Волк - это дикое животное. Живут они около десяти лет. Эти животные могут весить около 80 килограммов. Издалека волка можно перепутать с собакой. Но у него есть одно главное отличие - хвост. Он у волка всегда прямой и опущен книзу. Волк в отличие от собаки суров. Живут волки обычно семьей, а зимой объединяются в большие стаи. А с приходом весны эти стаи распадаются. Охотятся волки как на крупных животных, таких как кабан, косуля, так и мелких, например, зайцев, мышей. К сожалению, в настоящее время волки находятся под угрозой исчезновения, так как их уничтожают во время охоты, либо при защите домашнего скота. Но необходимо помнить о том, что волк является самым главным санитаром природы. Он убивает больных и умирающих животных. Лишив жизни волка, человек рискует погибнуть сам. Давайте беречь живую природу и ее обитателей!

**9 нчы бирем. Муса Җәлилнең “Ялгыз учак” шигырен укыгыз. Шигырьдә**

**кулланылган тропларны һәм стилистик фигураларны ачыклагыз, аларның төрен билгеләгез, әлеге тел-сурәтләү чараларының әсәрдә нинди функция үтәвен аңлатып языгыз. Иң югары балл – 6.//** Задание 9. Прочитайте стихотворение Мусы Джалиля “Одинокий костер” на татарском языке. Выпишите тропы и стилистические фигуры и укажите вид изобразительно-выразительного средства. Поясните, какую функцию выполняет каждый из них в лирическом произведении. Максимальный балл – 6.

Төн караңгы, учак яктым,
Тирә-ягым томан...
Мин диңгездә япа-ялгыз
Йөзгән кораб сыман.

Учагымның чаткылары
Томан ертып оча...
Чаткыларның яктылары
Киң бушлыкны коча.

Кызыл ялкын, телен сузып,
Уя җирнең битен.
Мин кайвакыт я сызгырып,
Яхут җырлап куям.

Томан аша ялтыраган
Утны күрмәсләрме?
Томан ертып ялтыраган
Җырга килмәсләрме?

**10 нчы бирем. Үзегез теләгән бер хикәягә тәкъдим ителгән план нигезендә тулы, бөтенлекле анализ ясагыз. Сезнең 200-250 сүз күләмендәге җавабыгыз тулы, төгәл, эзлекле һәм бөтенлекле булырга тиеш. Иң югары балл – 20. //** Задание 10. Выполните целостный анализ прозаического произведения на татарском языке по предложенному плану. Ваша работа должна представлять собой цельный, связный, завершённый текст на татарском языке. Рекомендуемый объём – 200–250 слов. Максимальный балл – 20.

1. Хикәянең темасын һәм идеясен, анда күтәрелгән проблемаларны билгеләгез, сюжетка нигезләнеп, әсәр исеменең мәгънәсен аңлатып языгыз.

*Определите тему, идею и проблематику данного произведения, объясните смысл названия рассказа.*

2. Хикәядә сурәтләнгән вакыйгаларга, геройларга һәм аларның эш-гамәлләренә карата автор фикерен, мөнәсәбәтен ачыклап языгыз.

*Авторское отношение к событиям, героям и их поступкам.*

3. Хикәянең төп сюжет элементларын билгеләгез (экспозиция, төенләнеш, вакыйгалар үстерелеше, кульминацион нокта, чишелеш).

*Определите основные элементы сюжетной линии рассказа (экспозиция, завязка, развитие действия, кульминация, развязка).*

4. Хикәядә катнашкан геройларны төп, ярдәмче, эпизодик кебек төркемчәләргә аерып языгыз һәм аларга характеристика бирегез: характерлары, үзара аралашу үзенчәлеге, персонажларның типиклыгы яки уникальлеге, портретларының үзенчәлекләре (төс-кыяфәтләре, киемнәре һ.б.).

*Разделите образы персонажей рассказа (главные, второстепенные или*

*эпизодические образы) и дайте им характеристику: характеры, взаимоотношения между персонажами, типичность или уникальность персонажей, своеобразие созданного образа человека: портрет (лицо, фигура, костюм).*

5. Хикәядә нинди тел-сурәтләү чаралары һәм әдәби алымнар кулланыла? Әсәрдә алар нинди функция үтиләр, язучы аларны нинди максатлардан чыгып файдалана?

*Какие художественные средства и приёмы создают особый эмоциональный фон рассказа? И какую функцию они выполняют в произведении?*

6. Әлеге хикәянең шул чорда иҗат иткән башка әдипләрнең әсәрләре арасындагы урынын билгеләгез. Аңа бүгенге карашлардан чыгып бәя бирегез.

*Определите место данного произведения среди произведений других авторов, написанных в этот период и дайте оценку произведения в контексте современного прочтения.*

5. Хикәягә карата үзегезнең шәхси мөнәсәбәтегезне, бәягезне җиткерегез.


*Выразите свое эмоционально-оценочное отношение к прочитанному.*

**Тулаем эш (1-10нчы биремнәр) 100 балл белән бәяләнә.**
**Максимальный балл за всю работу (задания 1-10) – 100**

**Бәяләү системасы һәм критерийлар**

**Система и критерии оценивания**

| Биремнәр | Дөрес җаваплар | Бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|---|
| **1 нче бирем** | Мәсәлән, 1) Батыр яуда беленер. [ба°ты´р йа°wда´ бэлэнэ´р].<br>2) Яхшының сүзе татлы. [йа°хшыны´ң сүзэ´ та°тлы´]. | **2 балл** мәкаль өчен (һәр мәкаль 1 балл белән бәяләнә).<br>**2 балл** сүзләргә дөрес транскрипция ясаган өчен (һәр мәкаль 1 балл белән бәяләнә). | **4 балл** |
| | | **2 балла** – за пословицы (по 1 баллу за каждую).<br>**2 балла** – за правильное транскрибирование пословиц (по 1 баллу за каждую). | **4 балла** |
| **2 нче бирем** | **Юлда** – юл+да – тамыр сүз, -да төрләндергеч кушымча алган, нигезе – юл;<br>Юлда – җөмләдә урын хәле, йөрсәм фигыленә бәйләнгән, алар арасында ияртүле бәйләнеш.<br>**Җырлап** – җыр+ла+п – ясалма сүз, -ла сүз ясагыч кушымча һәм -п төрләндергеч кушымча алган, нигезе – җырла;<br>Җырлап – җөмләдә рәвеш хәле, барам фигыленә бәйләнгән, алар арасында ияртүле бәйләнеш.<br>**Яшьлегем** – яшь+лек(г)+ем – ясалма сүз; -лек сүз ясагыч | **3 балл** сүзне морфемаларга дөрес таркаткан өчен куела (һәр сүз өчен 1 балл). Анализда хата булса, 1 балл алына;<br>**1,5 балл** сүзнең җөмләдәге синтаксик вазифасын дөрес билгеләгән өчен бирелә (һәр сүз өчен 0,5 балл).<br>**1,5 балл** сүзләр арасындагы бәйләнешне дөрес күрсәткәнгә бирелә (һәр сүз өчен 0,5 балл). | **6 балл** |
| | | **3 балла** – за правильный морфемный разбор слов (по 1 баллу за каждое слово). Если в | **6 баллов** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | кушымча һәм -ым төрләндергеч кушымча алган; нигезе – яшьлек.<br>Яшьлегем – җөмләдә ия; кабатлана фигыленә бәйләнгән. Алар арасында ияртүле бәйләнеш (хәәбәрлекле мөнәсәбәт). | морфемном анализе допущена ошибка, 1 балл за данное слово снимается;<br>**1,5 балла** – за правильное определение синтаксической функции (по 0,5 баллов за правильноопределенную функцию одного слова).<br>**1,5 балла** – за правильное определение виды синтаксической связи (по 0,5 балла за правильно определенный вид синтаксической связи одного слова). | |
| **3 нче бирем** | **1)** Синоним пары: иркен – киң, зур<br>Антоним пары: иркен – кысан.<br>**2)** Синоним пары: киң – зур, иркен.<br>Антоним пары: киң – тар.<br>**3)** Синоним пары: озын – зур.<br>Антоним пары: озын – кыска.<br>**4)** Антоним пары: юк - бар<br>**5)** Синоним пары: һәр – һәрбер, һәркайсы | **1 балл** дөрес табылган синоним һәм (яки) антоним пар өчен куела. (барлыгы 5 пар). | **5 балл** |
| | | **1 балл** – за каждую правильно приведенную пару синонимов или антонимов (их максимальное значение 5). | **5 баллов** |
| **4 нче бирем** | <br>Төркемнәр:<br>1) Уйлардан – тамыр сүз.<br>2) Иге-чиге – парлы сүз<br>3) Бәхетле, коштай, канатлана – ясалма сүзләр<br>4) Балачагым – кушма сүз | **3 балл** сүзләрнең төзелеше дөрес күрсәтелгән очракта куела (һәр сүз өчен 0,5 балл).<br>**1 балл** ясалыш ысулын дөрес билгеләгән өчен куела.<br>**1 балл** ясалыш ысулы ягыннан сүзләрне дөрес төркемләгән өчен куела. | **5 балл** |
| | | **3 балла –** за правильно указанные способы образования слов (по 0,5 балла за слово).<br>**1 балл** – за правильно составленную группу слов, образованных суффиксальным способом.<br>**1 балл** – за правильно составленную группу слов, образованных двумя способами – способом сложением и суффиксальным. | **5 баллов** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **5 нче бирем** | 1) *тынычлыгын алу*;<br>2) *баш вату*;<br>3) *кош томкандай*;<br>4) *җиңел сулап кую;* | **1 балл** һәр дөрес табылган фразеологизм өчен куела. | **4 балл** |
| | | **1 балл –** за каждый правильно указанный фразеологизм. | **4 балла** |
| **6 нчы бирем** | *1) Тора-бара әлеге ручка малайның тәмам тынычлыгын алды, 2) аңа карап утыра торгач, 3) кыңгырау шалтыраганны да 2) ишетмәде, 4) малайлар ишектән йөгереп чыга башлагач кына,2) кайда утыруын абайлап алды.*<br>Бу – катнаш кушма җөмлә. Ул 4 хәбәрлектән тора.<br>Беренче хәбәрлек – *ручка тынычлыгын алды*. Ул икенче хәбәрлеккә (*ишетмәде, абайлап алды*) санау интонациясе ярдәмендә бәйләнгән, алар арасында тезүле бәйләнеш;<br>Өченче хәбәрлек – *кыңгырау шалтыраганны*. Ул икенче хәбәрлеккә (*ишетмәде, абайлап алды*) төшем килеше кушымчасы ярдәмендә бәйләнгән, алар арасында иярттүле бәйләнеш. Синтетик иярчен тәмамлык җөмлә.<br>Дүртенче хәбәрлек – *малайлар чыга башлагач.* Ул икенче хәбәрлеккә (*ишетмәде, абайлап алды*) хәл фигыль кушымчасы ярдәмендә бәйләнгән, алар арасында иярттүле бәйләнеш. Синтетик иярчен вакыт җөмлә. Өченче һәм дүртенче хәбәрлек тиңдәш түгел. | **0,5 балл** кушма җөмләнең төрен дөрес билгеләгән өчен куела.<br>**1 балл** кушма җөмләнең компонентлары санын (хәбәрлекләр һәм аларның чикләрен) дөрес билгеләгәнгә бирелә.<br>**2 балл** хәбәрлекләр арасындагы бәйләнеш ысулын чараларны (җөмлә эчендәге һәр бәйләнеш төренә 1 балл) дөрес билгеләгән өчен куела.<br>**1,5 балл** хәбәрлекләр арасындагы бәйләүче чараларны дөрес күрсәткән өчен куела (һәр бәйләүче чара өчен 0,5 балл бирелә). | |
| | | **0,5 баллов** – за правильное определение вида сложного предложения.<br>**1 балл –** за правильное выделение частей многокомпонентного сложноподчинённого предложения.<br>**2 балла** – за правильное определение способов связи частей многокомпонентного сложноподчинённого предложения (по 1 баллу за правильное определение каждого вида связи между частями предложения**).**<br>**1,5 баллов** – за правильное определение средств связи между частями многокомпонентного сложноподчинённого предложения (по 0,5 баллов за правильное определение каждого средства связи). | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **7 нче бирем** | Проблема – кеше әйберен рөхсәтсез алу.<br><br>Автор позициясе – кешедән, кешенең әйбереннән көнләшү урлауга этәргеч була ала (герой Илһамның артыннан көнләшеп карап кала). Кеше әйберенә тию - бик начар күренеш (автор кара теләк дип атый).<br><br>Чишелеш – герой энисе, сеңлесе алдында ояла (кызарып китә). Герой үзенең начарлык кылганын аңлый (ручканы хуҗасына биргәч, аңа җиңел булып китә). | **2 балл** – проблема дөрес формалаштырылган; 0 балл – дөрес формалаштырылмаган яки бөтенләй әйтелми.<br>**3 балл** – текстка нигезләнгән аңлатма һәм 2 дәлил бар;<br>**2 балл** – аңлатма бар, ләкин дәлилләр тексттан китерелмәгән; 0 балл – текстка нигезләнгән аңлатма юк.<br>**3 балл** – проблемаган карата автор позициясе күрсәтелгән; 0 баллов – автор позициясе күрсәтелмәгән.<br>**3 балл** – эш мәгънәви бөтенлекккә ия, бәйләнешле һәм эзлекле тасвирланган;<br>**1 балл** – эш төгәл башкарылган, ләкин 2дән артык логик хата бар<br>**4 балл** – орфографик, пунктуацион, грамматик һәм сөйләм нормалары саклanган;<br>**2 балл** – 3-4 хатасы бар;<br>**0 баллов** –5 яки күбрәк хатасы бар. | **15 балл** |
| | | **0,5 баллов** – за правильное определение вида сложного предложения.<br>**1 балл** – за правильное выделение частей многокомпонентного сложноподчинённого предложения.<br>**2 балла** – за правильное определение способов связи частей многокомпонентного сложноподчинённого предложения (по 1 баллу за правильное определение каждого вида связи между частями предложения**)**.<br>**1,5 баллов** – за правильное определение средств связи между частями многокомпонентного сложноподчинённого предложения (по 0,5 баллов за правильное определение каждого средства связи). | |
| **8 нче бирем** | «Бүре»<br>Бүре – кыргый хайван. Алар ун ел чамасы яшиләр. Аларның авырлыгы 80 килограммга җитәргә мөмкин. Кайвакытта бүрене эт белән | Һәр 15 җөмлә 2 төп критерий буенча бәяләнә:<br>**1 балл** – җөмләнең мәгънәсе татар теле чаралары ярдәмендә төгәл тәрҗемә ителгән**.**<br>0 балл – мәгънә дөрес | **30 балл** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | бутарга мөмкин. Ләкин аның төп аермасы бар – койрыгы. Бүреләрнең койрыгы һәрвакыт туры була һәм аска карап тора. Бүре эттән аермалы буларак бик усал.<br>Бүреләр гаилә булып яшиләр, ә кышын зур көтү булып берләшәләр. Яз җиткәч, кабат көтү тарала. Бүреләр кабан, болан кебек эре хайваннар белән дә, куян, тычкан кебек ваклары белән дә тукланалар. Кызганычка каршы, бүгенге көндә бүреләргә юкка чыгу яный, чөнки ау һәм йорт хайваннарын саклаганда, алар күпләп юк ителәләр. әмма бүре табигатьнең иң төп санитары булуын онытырга ярамый. Ул авыру һәм үлеп баручы хайваннарны гына үтерә. Бүрене юк итеп, кеше үз гомерен куркыныч астына куя Әйдәгез, табигатьне һәм анда яшәүчеләрне саклыйк! | белдерелмәгән яки адекват тәрҗемә ителмәгән;<br>1 балл – фикер дөрес җиткерелгән; мәгънәви хаталар юк.<br>0 балл – мәгънә дөрес белдерелмәгән, хаталар бар.<br>0 балл – җөмлә тәрҗемә ителмәгән.. | |
| | | Каждое из 15 переведенных предложений текста оценивается по двум критериям, предполагающим получение конкретного количества баллов:<br>**1 балл** – адекватная передача содержания предложения из текста оригинала средствами языка перевода**.**<br>0 баллов – в случае наличия серьезного отклонения от содержания оригинала или неадекватной передачи содержания;<br>1 балл – выбор правильной формы передачи мысли в предложении на языке перевода (грамотное изложение, отсутствие ошибок).<br>0 баллов – при неправильном выборе формы выражения мысли в предложении на языке перевода (наличии ошибок, допущении неточностей в формулировках на родном языке).<br>0 баллов – при непереведенном предложении. | |
| **9нчы бирем** | **Троплар**<br>*Төн караңгы* – эпитет. Төннең билгесен җиткерүдә кулланыла;<br>*кораб сыман* – чагыштыру. Лирик геройны кораб белән чагыштыруда файдаланыла;<br>*Учагымның чаткылары*<br>*Томан ертып оча* – сынландыру. Җансыз предметны, күренешне җанлы итеп күрсәтеп, эмоциональлекне көчәйтә;<br>*Чаткыларның яктылары*<br>*Киң бушлыкны коча* – сынландыру. Җансыз предметны, күренешне җанлы итеп күрсәтеп, эмоциональлекне көчәйтә;<br>*Киң бушлык* - эпитет. Бушлыкның чиксезлеген, | **Тропларны һәм стилистик фигураларны билгеләү.**<br>**3 балл** – укучы шигырьдә кулланылган барлык тропларны һәм стилистик фигураларны да дөрес итеп билгели.<br>**2 балл** – укучы шигырьдә кулланылган барлык тропларны һәм стилистик фигураларны да ачыклап бетерә алмый.<br>**0 балл** – укучы шигырьдә кулланылган тропларны һәм стилистик фигураларны бөтенләй ачыкламый.<br>**Тропларның һәм стилистик фигураларның әсәрдә нинди функция үтәвен аңлату.**<br>**3 балл** – укучы шигырьдә | **6 балл** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | зурлыгын көчәйтүгә юнәлтелә;<br>*Кызыл ялкын* - эпитет. Ялкынның сыйфатын ачуда кулланыла;<br>*телен* – метафора. Образ тудыруда катнаша;<br>*уя җирнең битен* – сынландыру. Җансыз предметны, күренешне җанлы итеп күрсәтеп, эмоциональлекне көчәйтә;<br>*җир бите* – метафора. Образ тудыруда катнаша;<br>*ялтыраган җыр* – метафора. Җырны ут белән чагыштыруга, аның яктылыгын, маяк булуын ачуга юнәлтелә.<br>**Стилистик фигуралар.**<br>*Учагымның чаткылары*<br>*Томан ертып оча* – инверсия. Шигъри сөйләмгә эмоциональ төсмер бирә. | кулланылган барлык тропларның һәм стилистик фигураларның да функциясен дөрес аңлата.<br>**2 балл** – укучы шигырьдә кулланылган барлык тропларның һәм стилистик фигураларның да функциясен дөрес итеп аңлатып бетерә алмый.<br>**0 балл** – укучы шигырьдә кулланылган тропларның һәм стилистик фигураларның функциясен аңлата алмый. | |
| | | **Определение тропов и стилистических фигур.**<br>**3 балла** – учащийся выписал из текста все использованные в лирическом произведении тропы и стилистические фигуры.<br>2 балла – учащийся выписал из текста не все средства художественной выразительности.<br>0 баллов – учащийся не нашел в тексте ни одного средства выразительности.<br><br>**Пояснение тропов и стилистических фигур.**<br>**3 балла** – учащийся правильно пояснил, в чем заключается их суть каждого тропа или фигуры речи.<br>2 балла – учащийся смог пояснить суть не всех найденных в тексте художественных средств.<br>0 баллов – учащийся не пояснил суть найденных в тексте тропов и стилистических фигур. | **6 баллов** |
| **10 нчы бирем** | 1) Хикәянең темасын һәм идеясен, анда күтәрелгән проблемаларны билгеләгез, сюжетка нигезләнеп, әсәр исеменең мәгънәсен аңлатып языгыз. | 1) **3 балл** – укучы хикәянең темасын, идеясен, проблематикасын дөрес билгели. Әсәр исеменең мәгънәсен дөрес аңлата.<br>**2 балл** – укучы хикәянең темасын, идеясен, проблематикасын дөрес билгели, әмма әсәр исеменең мәгънәсен аңлата алмый.<br>**0 балл –** укучы хикәянең темасын, идеясен, проблематикасын дөрес билгели алмый, әсәр исеменең мәгънәсен аңлатмый. | **20 балл** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | 2) Хикәядә сурәтләнгән вакыйгаларга, геройларга һәм аларның эш-гамәлләренә карата автор фикерен, мөнәсәбәтен ачыклап языгыз. | 2) **3 балл** – укучы хикәядә сурәтләнгән вакыйгаларга, геройларга һәм аларның эш-гамәлләренә карата автор фикерен, мөнәсәбәтен дөрес билгели**.**<br>**2 балл** – укучы хикәядә сурәтләнгән вакыйгаларга, геройларга һәм аларның эш-гамәлләренә карата автор фикерен, мөнәсәбәтен билгеләүдә кыенлыклар кичерә, 1-2 сөйләм төгәлсезлеге һәм логик хата урын ала.<br>**0 балл** – укучы автор позициясен дөрес итеп аңлата алмый. | |
| | 3) Хикәянең төп сюжет элементларын билгеләгез (экспозиция, төенләнеш, вакыйгалар үстерелеше, кульминацион нокта, чишелеш). | 3) **3 балл** – сюжет схемасын билгеләүдә хаталар юк. Укучы терминологик аппаратны аңлап-белеп куллана. Сөйләм һәм стиль хаталары күзәтелми. Цитаталар һәм әсәргә сылтамалар урынлы файдаланыла.<br>**2 балл** – сюжет схемасын билгеләгәндә 1 хата күзәтелә. Цитаталар һәм әсәргә сылтамалар урынлы файдаланыла.<br>**1 балл** – сюжет схемасын билгеләгәндә һәм теоретик төшенчәләрне куллануда хаталар күзәтелә. Цитаталар һәм әсәргә сылтамалар бирүдә дә төгәлсезлекләр очрый.<br>**0 балл** – сюжет схемасы ачыкланмаган. | |
| | 4) Хикәядә катнашкан геройларны төп, ярдәмче, эпизодик кебек төркемчәләргә аерып языгыз һәм аларга характеристика бирегез: характерлары, үзара аралашу үзенчәлеге, персонажларның типиклыгы яки уникальлеге, портретларының үзенчәлекләре (төс-кыяфәтләре, киемнәре h.б.). | 4) **3 балл –** геройларга тулы, дөрес характеристика бирелә, аларның үзенчәлекләре тулысынча ачыла, төркемчәләре дөрес билгеләнә. Җавапта сөйләм хаталары күзәтелми. Цитаталар һәм әсәргә сылтамалар урынлы кулланыла**.**<br>**2 балл –** геройларга шактый тулы характеристика бирелә, аларның үзенчәлекләре ачыла, төркемчәләре дөрес билгеләнә. Җавапта бер сөйләм хатасы урын ала.<br>**1 балл** – төп геройларга характеристика гомуми генә бирелә, аларның үзенчәлекләре | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | тулысынча ачыкланып бетми.<br>**0 балл –** төп геройларга дөрес характеристика бирелми. Җавапта сөйләм хаталары еш очрый. | |
| | 1) Определите тему, идею и проблематику данного произведения, объясните смысл названия рассказа. | 1) **3 балла** – учащийся верно определяет тему, идею и проблематику произведения. Четко и ясно объясняет смысл названия произведения**.**<br>2 балла – учащийся верно определяет тему, идею и проблематику рассказа, но не смог объяснить смысл названия произведения.<br>0 баллов – **у**чащийся не может определить тему, идею и проблематику произведения, не может объяснить смысл названия произведения. | **20 баллов** |
| | 2) Авторское отношение к событиям, героям и их поступкам. | 2) **3 балла** – учащийся показал понимание авторской позиции к событиям, героям и их поступкам**.**<br>2 балла – **у**чащийся испытывает затруднения с анализом авторской позиции, есть 1-2 речевые и логические ошибки.<br>0 баллов – учащийся не смог сформулировать авторскую позицию. | |
| | 3) Определите основные элементы сюжетной линии рассказа (экспозиция, завязка, развитие действия, кульминация, развязка). | 3) **3 балла** – логических ошибок в определении основных элементов сюжетной линии нет. Учащийся владеет литературоведческими понятиями и терминами. Речевые ошибки отсутствуют. Цитаты и отсылки к тексту уместны.<br>2 балла – допущена одна ошибка в определении основных элементов сюжетной линии. Цитаты и отсылки к тексту уместны.<br>1 балл – допущено более одной ошибки, учащийся допускает ошибки в использовании литературоведческих понятий. Цитаты и отсылки к тексту не всегда уместны.<br>0 баллов – сюжетная схема не определена и не описана. | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 4) Разделите образы персонажей рассказа (главные, второстепенные или эпизодические образы) и дайте им характеристику: характеры, взаимоотношения между персонажами, типичность или уникальность персонажей, своеобразие созданного образа человека: портрет (лицо, фигура, костюм). | 4) **3 балла** – дается достаточно полная характеристика героев, своеобразие их образов, особенности взаимоотношений раскрыты достаточно полно. Речевые и стилистические ошибки отсутствуют. Цитаты и отсылки к тексту уместны**.**<br>2 балла – дается достаточно полная характеристика героев, допущена речевая ошибка.<br>1 балл – характеристика действующих лиц слишком общая, характер взаимоотношений между героями прозаического произведения раскрыт недостаточно.<br>0 баллов – образы действующих лиц (главных) и взаимоотношения между героями вообще не описаны или описаны с большим количеством речевых ошибок. | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 5) Какие художественные средства и приёмы создают особый эмоциональный фон рассказа? И какую функцию они выполняют в произведении? | 5) **3 балла** – учащийся верно определяет вид художественных средств и демонстрирует умение объяснить их роль в раскрытии идейно-эстетического содержания произведения и создании особого эмоционального фона рассказа. Учащийся владеет навыками использования литературоведческих понятий и терминов**.**<br>2 балла – в работе недостаточно полно раскрыта роль художественных средств в создании эмоционального фона рассказа, допущена одна ошибка в определении вида художественного средства. Учащийся допустил ошибку в употреблении литературоведческих понятий и терминов.<br>0 баллов – **у**чащийся не смог объяснить роль художественных средств в раскрытии идейно-эстетического содержания произведения и создании особого эмоционального фона рассказа. Учащийся не владеет литературоведческими понятиями и терминами. | |
| | 6) Определите место данного произведения среди произведений других авторов, написанных в этот период и дайте оценку произведения в контексте современного прочтения. | 6) **2 балла** – учащийся показал знание историко-литературного контекста: использует литературно-исторические факты и фоновый материал из области культуры и литературы, отсутствуют фактические ошибки.<br>1 балл – учащийся недостаточно хорошо знает историко-литературный контекст, допускает одну или две фактические ошибки.<br>0 баллов – Учащийся не может интерпретировать произведение в литературно-историческом контексте. | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 7) Выразите свое эмоционально-оценочное отношение к прочитанному. | 7) **3 балла** – учащийся демонстрирует умение выражать свои мысли, чувства и давать оценку прочитанному, отсутствуют речевые ошибки**.**<br>2 балла – учащийся достаточно хорошо выражает эмоционально-оценочное отношение к прочитанному, но допускает одну или две речевые ошибки в содержании ответа.<br>0 баллов – учащийся не может выразить эмоционально-оценочное отношение к прочитанному. | |

**Максимальный балл за всю работу (задания 1-10) – 100**
**Дөрес эшләнгән барлык биремнәр өчен иң югары балл (1-10 биремнәр) – 100**